ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2019 ел** «06» август **№** 589

**Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 4 декабрендә чыккан «Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында "гы 1208 номерлы карары белән расланган гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2010 елның 27 июлендә чыккан «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә йөрми торган балаларны төрле яклап үстерүне тәэмин итү, мәктәпкәчә белем бирү системасының яңа формаларын үстерү максатларында Арча муниципаль районы башкарма комитеты КАРАР бирә:

1. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 4 декабрендә чыккан «Гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турындагы Нигезләмәне раслау хакында»гы 1208 номерлы карары белән расланган гаилә мәктәпкәчә төркемнәрен оештыру турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Гаилә мәктәпкәчә төркеме белем бирү оешмасын гамәлгә куючы карары нигезендә төзелә.

Гаилә мәктәпкәчә төркеме оештыру мәсьәләсен хәл итүнең нигезе булып күпбалалы ата-ананың Арча муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе исеменә язган гаризасы тора.

Гаризага кушымта итеп түбәндәге документлар теркәлә:

- гариза бирүченең паспорт күчермәсе;

-белеме турында документ күчермәләре;

- гариза бирүченең хезмәт кенәгәсе;

-мәҗбүри медицина тикшерүе узу турында тамга (шул исәптән барлык гаилә әгъзаларының да) һәм гигиена белеме алу турында тамга сугылган шәхси медицина кенәгәсе;

-баланың туу турында таныклыгы күчермәсе (балаларның).»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.И.Гарифҗанов